ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.09.2021 Казан шәһәре № 498/2021

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында эшкә алучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә берүзе генә башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмалар идарәсендә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 168 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларын актуальләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында эшкә алучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә берүзе генә башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмалар идарәсендә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 13 июлендәге 168 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 29 апрелендәге 87 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), 3 пунктында «үземне җаваплы итеп билгелим» сүзләрен «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары А.Л.Штромга йөкләргә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 13 июлендәге 168 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында эшкә алучы вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә бирүзе генә башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциясез оешмалар идарәсендә түләүсез нигездә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт итү тәртибенә, 7 пунктында «кадрлар бүлегенең» сүзләрен «финанс исәбе, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром